ГЛАВА МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Мульма, ул.Центральная, 46а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мүлмә авылы, Үзәк ур, 46а

Тел./факс: +7(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**11 ноябрь 2024 ел** **№ 6**

# Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлегенең Красна авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

25.1 статьясына ярашлы., «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 22 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Уставы һәм "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" 2019 елның 22 октябрендәге 173 номерлы карарның (Советның 28.04.2020 № 199, 19.11.2020 № 13 карарлары редакциясендә)

**КАРАР ИТӘМ:**

1. 2024 елның 23 ноябрендә Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлегенең Красна авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 15 сәгать 00 минутка билгеләргә. Җыенны үткәрү адресы: ТР, Биектау районы, Красна авылы, Туры урамы, 12 нче йорт каршында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлегенең Красна авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

- Красна авылында җирләү урыннарын тоту (агачларны кисү, чүп-чарны чыгару, территорияне кисү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Мүлмә авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гатауллин